# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Яңа Мәлкән авыл җирлеге Дусай Кичү торак пунктында**
**2023 елда үзара салым кертү турында**

20 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Дусай Кичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1-2 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан,мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

   - Дусай Кичү торак пунктында Җәлил урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча түләү).

3. Җыенның нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://menzelinsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче: ________________ Нәҗметдинов З. И.
(имза)
Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ________________ Нәҗметдинов З. И.
(имза)